ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# “Ваклап сату базарлары турында һәм Россия Федерациясе Хезмәт кодексына үзгәрешләр кертү хакында” Федераль законның 24 статьясындагы 2 һәм 3 өлешләрендә каралган таләпләрне Татарстан Республикасы территориясендә куллану срогын билгеләү турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2015 елның 16 апрелендә
кабул ителде

**1 статья**

“Ваклап сату базарлары турында һәм Россия Федерациясе Хезмәт кодексына үзгәрешләр кертү хакында” 2006 елның 30 декабрендәге 271-ФЗ номерлы Федераль законның 24 статьясындагы 4 өлеше нигезендә әлеге Федераль законның 24 статьясындагы 2 һәм 3 өлешләрендә каралган таләпләр авыл хуҗалыгы базарларына һәм авыл хуҗалыгы кооператив базарларына карата, халык саны бер миллион кешедән артык булган шәһәрләр территорияләрендә урнашканнарыннан тыш, Татарстан Республикасы территориясендә 2020 елның 1 гыйнварыннан кулланыла дип билгеләргә.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Президенты
вазыйфаларын вакытлыча башкаручы Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2015 елның 25 апреле
№ 32-ТРЗ